РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail: Ishk.mam.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар Постановление

№ 1 31.01.2025 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Ишки авыл җирлегендә
җирлекара күмү урыннарында
җирләү буенча гарантияләнгән исемлек
нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен
раслау турында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль законның 9 статьясының 3 пункты һәм 12 статьясының 3 пункты (үзгәрешләр һәм өстәмәләрне исәпкә алып), «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Башкарма к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 9165,37 сум күләмендә билгеләргә һәм 2025нче елның 1 февраленнән 1 нче һәм 2 нче Кушымталар нигезендә гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 29 январендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында » №4 карарын гамәлдән чыкты дип танырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында («Нократ ("Вятка")) бастырып чыгагрырга һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында (http://mamadysh.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче /Р.К.Хафизов/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль район
Ишки авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31.01.2025 ел , 1карарына
1 нче № кушымта

2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча
гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар әзерләү | 0 |
| 2. Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 4216,11 |
| 3. Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1093,57 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3850,69 |
| Барлыгы | 9165,37 |

Татарстан  Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31.01.2025 ел , № 1 карарына
2 нче № кушымта

2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү  буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 1308,02 |
| 3.Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 3027,81 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1120,81 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3708,73 |
| Барлыгы | 9165,37 |